Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль районы
Олы Солтан  авыл җирлеге Советы

**КАРАР № 3**

Олы Солтан авылы                                                10 февраль, 2023 ел

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Олы Солтан авыл җирлеге Советының 2013 елның 26 июлендә кабул ителгән "Балык Бистәсе муниципаль районының Олы Солтан авыл җирлегендә муниципаль вазыйфаларны биләүче затларның һәм муниципаль хезмәткәрләрнең үз чыгымнары, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының чыгымнары турында белешмәләр бирү турындагы нигезләмәне раслау хакында»гы 8 номерлы карарга үзгәрешләр кертү хакында

2022 елның 1 апрелендәге  «Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында»  №90-ФЗ Федераль законы, Татарстан Республикасының 2020 елның 26 декабрендәге “Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында” № 97-ЗРТ законы кабул ителү сәбәпле, 2008 елның 25 декабрендәге «Коррупциягә каршы көрәш турында» №273-ФЗ Федераль законның 12.1 маддәсенә, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 40 маддәсенә тәңгәлләштереп, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы “Олы Солтан авыл җирлеге”  муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә,  Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Олы Солтан авыл җирлеге Советы  КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Олы Солтан авыл җирлеге Советының 2013 елның 26 июлендә кабул ителгән "Балык Бистәсе муниципаль районының Олы Солтан авыл җирлегендә муниципаль вазыйфаларны биләүче затларның һәм муниципаль

хезмәткәрләрнең үз чыгымнары, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының чыгымнары турында белешмәләр бирү турындагы нигезләмәне раслау хакында»гы 8 номерлы карарга түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

11 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итргә:

“11. Җир кишәрлеге, башка күчемсез милек объекты, транспорт чарасы, кыйммәтле кәгазьләр (оешмаларның устав (туплау) капиталында катнашу өлешләре, пайлары) цифрлы финанс активлары, цифрлы валюта сатып алу буенча средстволар алу чыганаклары турында белешмәләр, әгәр килешү суммасы  муниципаль вазыйфаны биләүче затның гомуми керемennән яки муниципаль хезмәткәрнең, аның хатыны (ире)нең  килешү башкарылар алдындагы соңгы өч ел эчендәге гомуми керемennән артса, "Интернет" челтәрендә муниципаль районның рәсми сайтында урнаштырыла, ә муниципаль районның рәсми сайтында бу мәгълүматлар булмаган очракта аларның соравы буенча массакүләм мәгълүмат чараларына бастырып чыгару өчен бирелә.».

2. Карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе  муниципаль районы Олы Солтан  авыл җирлегенең  Олы Солтан  авылы,  Р.Шәрәфиев  урамы, 12 йорт  адресы буенча урнашкан махсус мәгълүмат стендларында  һәм Татарстан Республикасы Балык  Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында  һәм http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге “Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы”нда урнаштырырга.

3. Карарның үтәлешенә контрольлек итүне  үземнең җаваплылыкта калдырам.

Татарстан Республикасы
Балык  Бистәсе муниципаль районы
Олы Солтан  авыл  җирлеге  башлыгы                                        Р.Р.Сөнгатуллин

СОВЕТ БОЛЬШЕСАЛТАНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ИНН 1634000725 ОЛЫ СОЛТАН АВЫЛ ЖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ